**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

____---------------______　　　　　　　　----------

**2020 елның 1 гыйнварыннан халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеген җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның минималь күләмен билгеләү һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик индексларын җайга салу нигезләре турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 03.12.2019г №1097 номерлы карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан Актаныш муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны расларга һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru һәм "Интернет" мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2019 елның 1 июленнән халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 21 июнендәге ПР-132 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе　　　　　　　　И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
__________ 2019 № ______
кушымта

2020 елның 1 гыйнварыннан халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Түләү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү берәмлеге, сумнарда |
|---|---|---|---|
| | | | Актаныш күпфат. йорт |
| | **Торак бина өчен түләү** | | |
| 1 | Торак бинаны капиталь ремонтлау | сум/кв. м. | 6,11 |
| 2 | Найм торак урыны | сум/кв. м. | 6,11 |
| 3 | Торак йорт белән идарә итү | сум/кв. м. | 3,15 |
| 4 | Йорт яны территориясен җыештыру | сум/кв. м. | 2,46 |
| 5 | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | сум/кв. м. | 3,05 |
| 6 | Сантехчелтәрләрне агымдагы ремонтлау | сум/кв. м. | 1,64 |
| 7 | Җылылык челтәрләренә агымдагы ремонт | сум/кв. м. | 1,41 |
| 8 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә агымдагы ремонт | сум/кв. м. | 0,92 |
| 9 | Дератизация | сум/кв. м. | 0,19 |
| 10 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә хезмәт күрсәтү | сум/кв. м. | 0,28 |
| 11 | Торак йортны карап тотуга электр белән тәэмин итү | сум/кв. м. | 0,68 |
| 12 | Сыек көнкүреш калдыкларын (ЖБО) чыгару | кеше/ай | 100 |
| 13 | Йорт эчендәге җилләтү каналларын һәм төтен юлларын техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м. | 0,25 |